# КАРАР

**22 ноябрь, 2023 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 21 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«Көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан кала, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2024 елда үзара салымны 1200 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Кара-Елга авылы урамнары юлларын вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- Кара-Елга авылы чишмәсен төзекләндерү (килешү буенча түләү);

- Кара-Елга авылында янгын гидрантларын урнаштыру,янгын комплектлау җиһазлары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина тоту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 67 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 35 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 35 кеше тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең Кара-Елга авылындагы халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны «Көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм инвалидлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 5 һәм аннан күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән, 75 яшьтәге һәм аннан да өлкәнрәк ялгыз пенсионерлардан кала, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Сәрдек авыл җирлегенең территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2024 елда үзара салымны 1200 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Кара-Елга авылы урамнары юлларын вак таш җәеп төзекләндерү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Кара-Елга авылы чишмәсен төзекләндерү (килешү буенча түләү);
- Кара-Елга авылында янгын гидрантларын урнаштыру,янгын комплектлау җиһазлары сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина тоту?

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Зур Сәрдек
авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Фаттахов

ОГРН 1021601153232
ИНН 1623001727